**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

«07» ноябрь, 2019 ел Калмаш авылы № 4

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Игенче авылында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 19 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Игенче авылы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Игенче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сумм күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм анны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сумм күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Игенче авылы мәчетен койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу;

2) балалар мәйданчыгы сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Игенче авылы, Үзәк урамы, 33 йорт, кибет янында

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Габдуллина